**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ
КОМЫРГУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОМОРГУЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422758 Республика Татарстан Атнинский район с. Коморгузя. Тел. 3-20-22

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«31» гыйнвар 2020 ел. № 1

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммммәтен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы “Җирләү һәм җирләү эше турында” Федераль закон, 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы “Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында “Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 нче номерлы “ 2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргҗа авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әтнә мунципаль районының Комыргуҗа авыл җирлегендә № 1 нче һәм № 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелгән хезмәт бәясен 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм 2020 елның 1нче февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Комыргуҗа авыл башкарма комитетының 2019 елның 5 ноябрендәге 8 номерлы «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр кыйммәтен раслау турында»гы карарын 2020 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Әтнә
муниципаль районы Комыргуҗа
авыл башкарма комитеты җитәкчесе Ф.Ф.Низамиев

Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа
авыл башкарма комитетының 2020
елнын 31 гыйнварындагы 1 нче
номерлы карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән
хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 4055,55 |
| 3.Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 489,77 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 1579,54 |
| Барлыгы | 6124,86 |

Әтнә муниципаль районы Комыргуҗа авыл башкарма комитетының 2020 елнын 31 гыйнварындагы 1 нче номерлы карарына 2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр бәясе исемлеге

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 220,39 |
| 3. Табут һәм башка күмү өчен кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3835,16 |
| 4. Зиратка үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) илтү. | 489,77 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 1579,54 |
| Барлыгы | 6124,86 |